РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ИСАНСУПОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСӘНСЕФ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

---

«08» июль 2024 ел Татар Бүләр авылы № 55

**«2024-2027 елларга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге Башкарма комитетының «20» июнь 2024 елдагы 54 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «2024-2027 елларга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «20» июнь 2024 елгы 54 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 нче кушымтаның 5.3 пунктындагы 5 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5.3. | Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арасында ел саен уздырыла торган конкурслар үткәрү һәм уңай иҗтимагый климат булдыру максатыннан массакүләм мәгълүмат чараларында үткәрелә торган чараларны яктырту | Җирлекнең Башкарма комитеты | Җирлек бюджеты (10 мең сум) | 2024 е.– 3 б.<br>2025 е.- 4 б.<br>2026 е.- 4 б.<br>2027 е. – 5 б. |

1.2. 1 нче кушымтаның 7 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Барлыгы - агымдагы финанслау 10 000,00 сум, шул исәптән:<br>- авыл җирлеге бюджеты - 10 000,00 сум.<br>Программаны район авыл җирлеге бюджетыннан финанслау күләме ел саен |

| | |
|---|---|
| | чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы законы нигезендә төгәлләштереләчәк.<br>Финанслау күләме кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арасында ел саен уздырыла торган конкурслар уздыруга һәм уңайлы шартлар тудыру максатында массакүләм мәгълүмат чараларында уздырыла торган чараларны яктыртуга юнәлтелгән.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. |

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет Житәкчесе Ф.Т.Сахбутдинова